# Презентация темасы:
# «Сөембикә манарасы»



*Башкарды: Рамазанова Л.Н.*
*Тикшерде: Ишкинина Л.К.*

**Сөембикә манарасы — Казан Кирмәне җирлегендә урнашкан манара. Элек татарларда Хан мәчете буларак аталды, ләкин соңарак русларда йөргән Башня Сююмбике исеме белән атала башлады.Татар ханлыгы чорыннан сакланып калган бердәнбер бина**







- **Бу манара хакында бик күп брошюралар, очерклар һәм фәнни мәкаләләр язылган, аның пәйда булу датасы хакында Казан галимнәренең бик күп буыннары бәхәс алып барды. Аларның бер ише Сөембикә манарасын татарныкы дип чыкты, ә икенчеләре ул бүгенге хәлендә Кремльгә руслар хуҗа булгач төзелгән дип раслыйлар.**



- Манараның исеме каян килеп чыгуы хакында тагын бер легенда безнең көннәргә кадәр килеп җиткән. Анда Иван Грозныйның Казан ханбикәсенең гүзәллеге хакында ишетеп, Казанга яучылар җибәрүе хакында сөйләнә. Горур Сөембикә рус патшасына барудан баш тарта. Шуннан соң Иван Васильевич зур гаскәр туплап, Казанга килә һәм шәһәрне камап ала. Кала халкын саклап калу өчен Сөембикә кияүгә чыгарга ризалаша, ләкин рус патшасы алдына җиде көн эчендә Казандагы иң биек манара төзү шартын

- Кызыл кирпечтән салынган 58 метр биеклектәге Сөембикә манарасының чыннан да җиде ярусы бар, алар биеклекләре һәм күләмнәре белән төрле-төрле. Күзәтү манарасының иске нигезендә салынган көнбатыш ягы тотрыклырак булып чыкканга, манара төзелеш тәмамлангач ук көнчыгышка таба авыша башлый. Бу авышу фәкать XX гасыр башында гына күренә башлый. Манараны тимер беркеткечләр белән ныгыталар. Ләкин манара «авышуын» дәвам итә һәм 1930 елга аның авышлыгы 1 метр һәм 28





- 90 нчы еллар башында уздырылган торгызу эшләреннән соң авышу 109 метр дәрәҗәсендә туктатыла. Хәзер Сөембикә манарасы дөньядагы иң «авыш» манара булып тора. Бу архитектура һәйкәле, Париж өчен Эйфель манарасы яисә Нью-Йорк өчен Азатлык статуясы кебек, безнең шәһәрнең символына әверелде.





- ***Хәзер манараның нигезе ныгытылган, манара үзе реставрацияләнгән. Сөембикә манарасына керергә ярамый, әмма тыелган булгач, аның диварлары кешене үзенә аеруча җәлеп итеп тора булса кирәк, эчендәге агач култыксаларга имза куярга теләүчеләр дә байтак. Диварлардагы граффитилар арасында XXI гасырда төшерелгәннәре дә бар.***



- ***Сөембикә манарасы — Казанның танылган архитектура символы.Казанлылар да, Татарстан башкаласын яратучылар да XXI гасырда манара керү өчен яңадан ачык булыр һәм максатчанлык, матурлык һәм чыдамлык символы булып калыр дип өметләнәләр***






- ***Игътибарыгыз өчен рәхмәт!***